| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Казан ш. № 688-131/тэ-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.07.2021 № 111-14/тэ-2021 карарына үзгәрешләр кертү һәм «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.07.2021 №111-14/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2022 елга җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2020-2022 елларга тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 13.07.2021 № 111-14/тэ-2021 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «кушымтасына» сүзен «1 нче кушымтасына» сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2020-2022 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.»;

кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.07.2021 № 111-14/тэ-2021 карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2021 № 688-131/тэ-2021 карары редакциясендә)

## «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2020-2022 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясе чыганагы төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | Пар |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | |
| 1 | «ПЭСТ» ҖЧҖ | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 319,83 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 337,49 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 337,49 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 351,96 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 351,96 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 398,67 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.07.2021 № 111-14/тэ-2021 карарына
2 нче кушымта (Татарста Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
17.12.2021 № 688-131/тэ-202
карары редакциясендә)

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2020-2022 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык челтәренең матди характеристикасына технологик югалтулар күләменең мөнәсәбәте | Технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «ПЭСТ» ҖЧҖ | 2020 | 5961,89 | 1 | 3,36 | 7665,00 |
| | | 2021 | Х | 1 | 3,36 | 7665,00 |
| | | 2022 | Х | 1 | 3,36 | 7665,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге